| | | |
|---|---|---|
| Республика Татарстан<br><br>Исполнительный комитет<br>Менделеевского<br>муниципального района | | Татарстан Республикасы<br><br>Менделеевск муниципаль<br>районы<br>башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.07.2026 Менделеевск ш. № 481

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 23 декабрендәге 750 нче номерлы карары белән расланган Менделеевск шәһәре территориясендә белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 бүлегендәге 2.5.1 пунктының 4 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк булган очракта һәм федераль закон нигезендә мондый шәхси күрсәткечләрне эшкәртү күрсәтелгән зат ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртүгә ризалыгын алуын раслый торган өстәмә документлар тапшыра. Ризалык алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин. Әлеге өлешнең гамәлдә булуы хәбәрсез югалган дип танылган затларга һәм урнашу урыны вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнмәгән эзләнүче затларга кагылмый.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга www.mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Исканов